Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

16.03.2022 ел

Менделеевск ш.

№177

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы халкына
үзәкләштерелгән хәбәр итүнең
муниципаль автоматлаштырылган системасын
файдалануга кертү турында

Россия Федерациясе Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 578 номерлы боерык нигезләмәсе, "Халыкка хәбәр итү системалары турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2020 елның 31 июлендәге 365 номерлы Россия Элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының боерыгы, "Татарстан Республикасы халкына хәбәр итү системаларына эксплуатация-техник хезмәт күрсәтүне оештыру буенча нигезләмәләрне раслау турында" ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һәм ТР Цифрлы үсеш министрлыгының 2020 елның 24 декабрендәге П/504/414 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасының "Татарстан Республикасы халкына хәбәр итү системаларына эксплуатация-техник хезмәт күрсәтүне оештыру нигезләмәләрен раслау турында" 2021 елның 2 сентябрендәге 16-21р номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм юкка чыгару һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенең күрсәтмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасының Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль системасы (алга таба - Система) составында Менделеевск муниципаль районы буенча халыкка хәбәр итүнең муниципаль системасын 2022 елның 1 мартыннан файдалануга кертергә.

2. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалыгы һәм инфраструктура үсеше буенча беренче урынбасары Л.М. Зариповка түбәндәгеләрне оештырырга:

- җиһазларның сакланышы өчен җаваплы затларны билгеләп кую, өзлексез эш башкару һәм системага вакытында техник хезмәт күрсәтү;
- системаның эшләве һәм эксплуатациясе өчен җаваплы вазыйфаи затларны үз вакытында укытуны тәэмин итү;
- халыкка, хәбәр итү сигналларын алганда, эксплуатацияләүне оештыру һәм системаны әзерләү буенча күнегүләр уздырганда, гамәлләр тәртибенә ел саен өйрәтү.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, ТКХ һәм инфраструктура үсеше буенча беренче урынбасары Л.М.Зариповка йөкләргә

Җитәкче Р.И.Беляев